ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2025 ел Баулы шәһәре №20

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 декабрендәге 27 номерлы карар белән расланган, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 декабрендәге 27 номерлы карар белән расланган, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2.1.пунктта:

в) пунктчасында «Эшләр күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибендә гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү вариантлары булырга тиеш» сүзләрен «Күрсәтелгән бүлек» сүзләрен, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1-15 статьясындагы 13-15 өлешләрендә күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибендә каралган очракларда административ регламент структурасына кертелмәскә мөмкин.» сүзләренә алмаштырырга;

в) пунктчасында «Эшләр дәүләт яисә муниципаль хезмәтне күрсәтү вариантларында булырга тиеш, ул күрсәтелгән хезмәтләрне гомуми билгеләре белән берләштерелгән

мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә ала» сүзләрен «Күрсәтелгән бүлек «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 13.1-15 өлешләрендә күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибендә каралган очракларда административ регламент структурасына кертелмәскә мөмкин.» сүзләре белән алмаштырырга;

пунктча

г) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актында каралган башка нигезләмәләр.»;

д) пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2.1. пунктның җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.3.пунктта:

д) пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

к) пунктчасында «мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органга яисә күпфункцияле үзәккә турыдан-туры мөрәҗәгать иткән очракта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров